СОВЕТ
НОВОБУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Вокзальная, дом 31,
П.ж.-д.ст.Бурундуки, Дрожжановский район 422490

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БОРЫНДЫК
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Вокзал урамы, 31 нче йорт,
Борындык тимер юл ст. поселогы,
Чүпрәле районы
422490

Тел.: (84375) 3-17-45, 3-17-03, факс: (84375) 3-17-45, e-mail: Nbur.Drz@tatar.ru,
www. Nbur -drogganoe.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

Борындык тимер юл станциясе поселогы

2021 нче елның 20 декабрь № 17/3

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Җир кодексы, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 07.07.2003 елдагы 112-ФЗ номерлы Закон нигезендә, прокурор протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 гыйнварындагы 45/1 номерлы карары (09.04.2019 елдагы 66/1, 25.02.2021 елдагы 7/2, 01.06.2021 елдагы 10/1 номерлы редакциясендә) белән расланган "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә" түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **16 статьяның 1 пунктында** «капиталь төзелеш» сүзләреннән соң «мондый рөхсәт бирү турында гариза кергән көннән алып унбиш эш көне эчендә әзерләнә һәм» сүзләрен өстәргә;

2) **30 статьяда**:

а) **2 пунктка** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «6) территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итү.»;

б) **6 пунктта** «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн» сүзләренә алмаштырырга;

3) **36 статьяның 8 пунктындагы** дүртенче абзацын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән алмаштырырга:

"Җир асты байлыкларының аерым участокларыннан файдалану ил оборонасын

һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү, җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында чикләнергә яисә тыелырга мөмкин.

Торак пунктлар һәм территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану халыкның тормыш һәм сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохитне саклауга, биналарның һәм корылмаларның сакланышына куркыныч тудырырга мөмкин булган очракларда чикләнергә яисә тыелырга мөмкин, тау эшкәртмәләренең, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларның сакланышын да кертеп.

Махсус сакланылучы табигать территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану аларның территорияләрен махсус саклау режимы нигезендә гамәлгә ашырыла.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтының авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгы:  В.Г. Ранцев